МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.07.2019 Казан шәһәре № 592 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы У.Д. Гапаровага йөкләргә.

**Министр** **И.Х. Әюпова**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2019 елның 1 июлендәге 592 од номерлы боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү (алга таба – Министрлык, аккредитация) тәртибен регламентлаштыра.

1.2. Аккредитация срогы чикләнмәгән. Массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе теләге белән аккредитация төгәл бер редакция йөкләмәсен үтәү өчен кирәк булган срокка яки аккредитацияләнгән журналистны аның вакытлыча булмавы очрагында алмаштыру өчен (вакытлыча аккредитация) башкарылырга мөмкин.

## II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Аккредитация алуга теләсә кайсы милекчелек рәвешендәге һәм гамәлгә куючыларның теләсә нинди составындагы массакүләм мәгълүмат чаралары, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен аның Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршындагы аккредитациясенең раслануы зарур.

## III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитация алуга гариза массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы белән Министрлыкка күрсәтелгән гаризаның Министрлык тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирә торган теләсә кайсы ысул белән тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, эш һәм кәрәзле телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турындагы таныклыкның датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлыча аккредитация алуга гаризада шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аны үтәү срогы күрсәтелә, ә аккредитацияләнгән журналистны аның вакытлыча булмавы сәбәпле алыштырган очракта – аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм алмаштыручы журналистны аккредитацияләү вакыты күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитациясен раслаучы документларның күчермәләре беркетелә.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитацияләү турында (аккредитацияләүдән баш тарту турында) карар Татарстан Республикасы юстиция министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) тарафыннан гариза кергән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар, министрның тиешле боерыгы чыккан көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә аның редакция тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирә торган теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсус юнәлештә эшләгән очракта (реклама тарату, эротик басмалар) аккредитацияләүдән баш тартыла.

3.6. Гаризаны карау, министрның аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында боерыгы проектын әзерләү, шулай ук кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә хәбәр итү Министрлыкның өлкән белгече (матбугат секретаре) тарафыннан әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

чарада катнашырга;

чара турында Министрлык карамагында булган рәсми документларның (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмат-белешмә, статистика, аналитика һәм башка материаллары) күчермәләрен алырга;

бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүмат-белешмә материаллары белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокукларга.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә бурычлы:

массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаса, чараның регламентын үтәргә һәм аның барышына катнашмаска;

чарада катнашучыларның эшчәнлегенә комачауламаска;

басма материалларда (эфирда эшләгәндә) Министрлык тарафыннан бирелгән пресс-релизлардан, мәгълүмат-белешмә, статистика, аналитика һәм башка материаллардан файдаланган очракта, мәгълүмат чыганагына сылтама ясарга;

үз һөнәри эшчәнлеген башкарганда Министрлык эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.